Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр керту хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2003 елның 11 апреленда кабул ителде

1 статья. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6-7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 10 (8)) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 2 статья. **Татарстан Республикасында ветеринария эшен хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасында ветеринария эшен хокукый җайга салу федераль законнар, әлеге Закон һәм башка норматив хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.».

2. 4 статьяда:

исемендә «һәм идарәсе» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ветеринария эше өлкәсендә җирле үзидарә органнары карамагына түбәндәгеләр керә:

– тиешле территорияләрдә, хуҗалыкларда һәм ишегалларында хайваннарның куркыныч авыруларын бетерүгә юнәлдерелгән карантин, хуҗалык эшчәнлегенең махсус шартларын һәм режимнарын урнаштыру һәм юкка чыгару;

– авыл хуҗалыгы предприятиеләре, терлекчелек фермалары, комплекслары, терлекләрдән алынган продукцияне һәм чималны эшкәртү буенча башка предприятиеләр, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыклары эшчәнлеге зонасында әйләнә-тирә мохитнең санитар торышын тикшереп торуны оештыру;

ветеринария билгеләнешендәге чараларны җитештерү буенча предприятиеләр булдыруга һәм үстерүгә ярдәм итү;

– терлекләрнең йогышлы һәм массакүләм йогышсыз авыруларын профилактикалауны оештыру һәм аларга каршы көрәш буенча карарлар кабул итү;

– авыл хуҗалыгы предприятиеләренең, крестьян (фермер) һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның терлекләренә ветеринария хезмәте күрсәтүне оештыру мәсьәләләрен карау һәм хәл итү;

– терлекләрнең йогышлы авыруларын профилактикалау һәм бетерү программаларын карау һәм раслау;

– терлекләрнең инфекцияле, инвазион һәм массакүләм йогышсыз авыруларын, эпизоотияләрне кисәтү һәм аларны бетерү гамәлләрен тормышка ашыру;

– авырулардан һәм кырылулардан терлекләрнең баш саны кимү буенча, терлекчелек продукциясенең сыйфаты төшү буенча чаралар күрү.»;

4 пунктны төшереп калдырырга.

3. Закон текстында тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе» сүзләрен тиешле килешләрдә «ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле республика органы» сүзләренә алмаштырырга.

4. 5 статьяда:

1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы» сүзләрен «Татарстан Республикасында» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы» сүзләрен «Татарстан Республикасында» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле республика органы башлыгы, Россия Федерациясенең ветеринария өлкәсендәге вәкаләтле органының буйсыну тәртибендә югарырак җитәкчесе белән килешеп, эш урынына билгеләп куела һәм эш урынныннан азат ителә.»;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы, районнарның һәм шәһәрләрнең администрацияләре белән килешеп,» сүзләрен «законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә» сүзләренә алмаштырырга.».

5. 8 статьяда:

1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасының» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дәүләт ветеринария күзәтчелеге федераль законнар нигезендә дәүләт ветеринария хезмәтенең урындагы затлары тарафыннан башкарыла.».

6. 9 статьяның 1 пунктында:

«а» пунктчасында «Татарстан Республикасының» сүзләрен төшереп калдырырга;

«г» пунктчасында:

беренче абзацта «Дәүләт хакимияте һәм идарәсе» сүзләрен «Башкарма хакимият һәм җирле үзидарә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасының» сүзләрен төшереп калдырырга.

7. 10 статьяда:

1 пунктта «дәүләт идарәсе органнары» сүзләрен «башкарма хакимиятнең тиешле органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасының гамәлдәге» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта «Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары» сүзләрен «Башкарма хакимият һәм җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга.

8. 16 статьяда:

исемендә «Дәүләт идарәсе» сүзләрен «Башкарма хакимиятнен, жирле үзидарә» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Терлекләрнең инфекцияле һәм массакүләм инфекциясез авырулары Татарстан Республикасының билгеле бер территориясендә һәм торак пунктларында килеп чыккан очракта, дәүләт ветеринария хезмәте органнары тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, районнарның һәм шәһәрләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан карантин яисә башка чикләүләр кертелә.»;

икенче абзацта «күрсәтелгән» сүзен төшереп калдырырга, «дәүләт идарәсенең» сүзләрен «башкарма хакимиятнең» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасының» сүзләрен төшереп калдырырга.

9. 18 статьяда:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 статья. **Терлекләрне аерып алу һәм терлекчелек продукциясен тартып алу»;**

беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юкка чыгарганда баш дәүләт ветеринария инспекторы карары буенча терлекләр аерып алынырга һәм терлекчелек продукциясе тартып алынырга мөмкин.»;

икенче өлештә «Татарстан Республикасының баш дәүләт ветеринария инспекторы билгели» сүзләрен «федераль закон нигезендә билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче өлештә «конфискацияләнә» сүзен «тартып алына» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче өлештә «терлекләрне яки терлекчелек продукциясен тартып алу» сүзләрен «терлекләрне аерып алу яисә терлекчелек продукциясен тартып алу» сүзләренә алмаштырырга.

10. 19 статьяның исемендә һәм текстында «Татарстан Республикасы» сүзләрен «Татарстан Республикасында» сүзләренә алмаштырырга.

11. 20 статьяның икенче өлешендә «предприятиеләр, оешмалар җитештерә торган яисә гражданнар тарафыннан базарларда сатыла торган» сүзләрен «предприятиеләр, оешмалар, гражданнар тарафыннан җитештерелә, алар тарафыннан, шулай ук сәүдә предприятиеләре тарафыннан базарларда реализацияләнә торган» сүзләренә алмаштырырга.

12. 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21 статья. **Дәүләт ветеринария хезмәте идарәсе органнарының һәм учреждениеләренең башка дәүләт органнары һәм учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлеге**

Дәүләт ветеринария хезмәте идарәсе органнары һәм учреждениеләре гражданнарның сәламәтлеген, кешеләр һәм хайваннар өчен уртак авырулардан саклау мәсьәләләре буенча үз компетенциясе чикләрендә шуна вәкаләтле дәүләт органнары һәм учреждениеләре белән законнар нигезендә даими рәвештә үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.».

13. VI бүлекнең исемендә «Татарстан Республикасының» сүзләрен «Татарстан Республикасында» сүзләренә алмаштырырга.

14. 22 статьяда:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт ветеринария хезмәтен финанслау чыганагы – төрле дәрәҗәдәге бюджетларның акчалары, шартнамәләр буенча ветеринария эшләрен башкарган өчен кергән акчалар, шулай ук законнар нигезендә башка акчалар.»;

2 пунктта «җирле үзидарә бюджеты» сүзләрен «җирле бюджет» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ветеринария гамәлләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан финанслау чыгымнарын планлаштыру бюджетның чыгымнар өлешендә «Ветеринария» дигән аерым бүлекчәдә карала.».

15. VIII бүлекне төшереп калдырырга.

2 статья. Әлеге Закон, Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары вәкәләтләре чоры тәмамланган көннән үз көчснә керә торган 1 статьясының 2 пунктындагы өченче-унөченче абзацларыннан, 8 пунктындагы дүртенче, бишенче абзацларыннан гайре, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКИ ПРЕЗИДЕНТА АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2003 елның 7 мае
№ 12-ЗРТ